| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**24.03.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 782** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 августындагы 1525 номерлы карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 августындагы 1525 номерлы карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районы авыл территорияләрен комплексы үстерү» муниципаль программасын кушымтада бирелгәнчә яңа редакциядә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек , массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 мартындагы
782 номерлы карары белән
расланды

**«2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» (алга таба- Программа) |
| Программаны тормышка ашыру срогы | 2020-2025 еллар |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасында дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 08 апрелендәге 235 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында»» 2019 елның 20 сентябрендәге 851 номерлы карары. |
| Программаның җаваплы башкаручысы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчеләре | «Зеленодольск муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ;<br>«Зеленодольск муниципаль районы төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ;<br>Башкарма комитетның социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлеге;<br>«Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ; |
| Ярдәмче программаны уртак башкаручылар | Юк |
| Программаның максатлары | Авыл халкының санын саклап калу һәм арттыру;<br>авыл территорияләрендә уңайлырак һәм ансат тормыш шартлары булдыру;<br>авылга һәм авылча яшәү рәвешенә уңай караш формалаштыру |
| Программаның бурычлары | төбәк программалар нигезендә авыл халкының һәркем сатып ала алырлык һәм комфортлы торакка ихтыяҗын |

| | |
|---|---|
| | тәэмин итү;<br>төбәк программалары нигезендә салаларның һәм авылларның социаль-инженерлык төзелеше дәрәҗәсен күтәрү;<br>авылга шәһәр халкын җәлеп итеп, авыл халкы санын саклап калу һәм арттыру; |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2020-2025 еллар |
| Программаның максатчан күрсәткечләре | Авыл территорияләрендә авыл халкын һәркем сатып алырлык комфортлы торак белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, торак шартларын яхшырту;<br>авыл территорияләрен социаль - инженерлык белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү |
| Программаны финанслау күләмнәре, финанслау чыганаклары<br>. | Программаны финанслауның гомуми күләме<br>85 405 353 (сиксән биш миллион дүрт йөз биш мең дүрт йөз илле өч) сум 34 тиен, шул исәптән:<br>- федераль бюджет акчалары - 59 304704 (илле тугыз миллион өч йөз дүрт мең җиде йөз дүрт) сум 63 тиен;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 25 384986 (егерме биш миллион өч йөз сиксән дүрт мең тугыз йөз сиксән алты) сум 81 тиен;<br>- муниципаль районның җирле бюджеты акчалары - 715 661 (җиде йөз унбиш мең алты йөз алтмыш бер) сум 90 тиен.<br>Программаны гамәлгә ашыруга акчалар ел саен анykланачак һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырылачак, «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы карары авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту, авыл территорияләрен төзекләндерү чараларына тиешле финанс елы кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга кертеләчәк. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә ирешү түбәндәгеләрне булдырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>- авылда тормыш сыйфатын күтәрү;<br>- авыл халкының муллыгын һәм эш белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү;<br>- авыл халкын һәркем сатып ала алырлык һәм комфортлы торак белән тәэмин итү:<br>-авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен гомуми мәйданы 2 976,1 кв. метр булган торакны файдалануга тапшыру күләме;<br>авыл территорияләрен социаль - инженерлык белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү:<br>- авыл территорияләрен төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру 33 берәмлек тәшкил итәчәк;<br>Нәтиҗәлелек күрсәткече программа юнәлешләрен куллану күрсәткече нигезендә бәяләнә.<br>Программа юнәлешләреннән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүләрдә каралган нәтиҗә |

| | |
|---|---|
| | күрсәткеченең чынлыкта ирешелгән күрсәткечләрен чагыштыру юлы белән башкарыла. |

## 1. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсендә эшчәнлек өстенлекләре, төп проблемалар, аларның чишелешен бәяләү һәм үсеш фаразы.

Әлеге Программа «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе Дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысасында эшләнде;

Авыл территорияләрен комплекслы үстерү дигәндә авыл территорияләренең социаль һәм икътисадый куәтен саклап калу максатларында авыл тормышының сыйфатын һәм тормыш дәрәҗәсен тотрыклы күтәрүне тәэмин итү өчен шартлар тудыруны аңларга кирәк.

Зеленодольск муниципаль районы территориясе составына түбәндәге җирлекләр керә: 2 шәһәр тибындагы поселок, 21 авыл җирлеге

Район үсеше хәзерге этапта республика ягыннан авыл территорияләрен үстерүгә игътибар артуы белән характерлана.

Авылда яшәү шартларын яхшырту, башка факторлар белән беррәттән, аграр өлкәдә инвестицион активлыкны арттыруга, социаль хәлне яхшыртуга ярдәм итте;

Шул ук вакытта гамәлгә ашырылган чаралар авыл территорияләренең икътисадый потенциалын тулысынча һәм нәтиҗәле файдалану һәм авыл халкының тормыш сыйфатын күтәрү өчен җитәрлек түгел;

Территорияләрне тотрыклы үстерү чараларын гамәлгә ашыруда дәүләтнең ролен көчәйтү максатчанлыгы түбәндәгеләргә нигезләнгән:

- авыл территорияләрен тотрыклы үстерү максатчан җайланмаларының авылларда тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын арттыру өлешендә Россиянең социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре белән үзара бәйләнеше, аграр һәм икътисадның башка секторларын икътисадый үстерү өчен социаль нигезләр булдыру;
- авыл территорияләренең социаль проблемаларын хәл итүгә системалы якын килүне таләп итүче озак вакытка исәпләнгән характеры;
- авылның проблемалы мәсьәләләрен хәл итүнең дәүләт ярдәмен җәлеп итүне таләп итә торган чыгымнарның югары дәрәҗәдә булуы.

Программаның максатларына ирешү авыл территорияләрендә яшәү шартларын яхшыртуга, агросәнәгать комплексында һәм тулаем авыл икътисадында инвестицион активлыкны үстерү өчен уңай шартлар тудыруга ярдәм итәчәк.

Программа максатларына ирешү өчен авыл территорияләрен комплекслы үстерү өлкәсендә куелган бурычларны хәл итү кирәклеген нигезләү булып түбәндәгеләр тора:

- авыл җирендә хезмәт потенциалын формалаштыруга сизелерлек йогынты ясый торган уңай булмаган демографик хәл;
- авыл территорияләрендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешнең түбән дәрәҗәсе;
- авыл җирендә торак базары үсешенең һәм авыл халкы өчен торак шартларын яхшырту проблемаларын хәл итү мөмкинлегенең түбән дәрәҗәсе;
- авыл җирлегенең яшәү тирәлеге буларак җәлеп итүчәнлеге һәм миграцион хәлләр үсеше, шул исәптән авыл яшьләре арасында да;
- авыл халкының социаль активлыгы түбән дәрәҗәдә;
- җәмгыятьтә авыл территорияләрен үстерү перспективаларына уңай караш булмау.

Шулай итеп, әлеге муниципаль программаны эшләү зарурлыгы авыл территорияләрен комплекслы үстерү өлкәсендә эшчәнлекнең төп юнәлешләрен актуальләштерү ихтыяҗы белән билгеләнә.

## 2. Программаның максатлары, бурычлары һәм көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләре, аны тормышка ашыру сроклары

Программаның максатлары булып авыл территорияләрендә тормыш эшчәнлегенә уңай шартлар тудыру һәм авылга һәм авыл тормышына уңай мөнәсәбәт формалаштыру тора.

Максатларга ирешү өчен авыл халкының үтемле (һәркем өчен мөмкин булган) һәм уңайлы торакка ихтыяҗларын тәэмин итү, авылны социаль-инженерлык ягыннан төзекләндерү.

Булган потенциалны нәтиҗәле файдалану, дәүләт ярдәме һәм бюджеттан тыш инвестицияләрне җәлеп итү куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Куелган максатларга һәм бурычларга ирешү түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:

- авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен гомуми мәйданы 2 976,1 кв. метр булган торакны файдалануга тапшыру;
- авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү проектларын гамәлгә ашыру;
- 33 берәмлек күләмендә авыл территорияләрен төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру.

Программа авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуны һәм торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелешен үз эченә ала.

Программаның нәтиҗәләрен бәяләүнең максатлары, бурычлары, индикаторлары төп чаралар кысаларында 1 нче таблицада китерелгән.

Авыл территорияләрен комплекслы үстерү проблемасын хәл итү авыл халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуның тотрыклы үсешенә күчүнең мөһим өлеше булып тора.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру срогы: 2020-2025 еллар.

## 3. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең агымдагы торышына характеристика.

Авыл территорияләрен комплекслы үстерү проблемасын хәл итү авыл халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуның тотрыклы үсешенә күчүнең мөһим өлеше булып тора.

Хәзерге вакытта агросәнәгать комплекслары алдына куелган азык-төлек белән тәэмин итү буенча бурычларның һәм авыл җирендә хезмәт кадрларының сыйфаты арасында туры килмәү күзәтелә, бу авыл җирендә яшәүче халыкның миграциясенә бәйле.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларының максатлары - авыл халкын һәркем сатып алырлык уңайлы торак белән тәэмин итү, авыл җирлегендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту мөмкинлеген арттыру түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыру күздә тотыла:

- авыл территорияләрендә торак төзү һәм сатып алу өчен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районның җирле бюджеты акчалары исәбеннән социаль түләүләр бирү;
- наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак төзелешен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән алга таба сатып алу хокукы белән финанслашу;
- торакны төзегәндә (сатып алганда) ташламалы ипотека торак кредитлавы һәм ана (гаилә) капиталы механизмнарын файдалану;

- торак өлкәсендә инвестиция активлыгын стимуллаштыру нигезендә авыл җирлегендә торак төзелеше күләмнәрен арттыру.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга Зеленодольск муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү, гражданнарга торак төзүгә (сатып алуга), шулай ук районда торак төзү буенча наем шартнамәсе буенча бирелә торган чараларга социаль түләүләр бирү юлы белән субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларны, социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын комплекслы төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру авыл территорияләрен төзекләндерү юнәлешендә гамәлгә ашырыла.

Авыл территорияләрен үстерүнең объектив үзенчәлекләрен һәм шәһәр территорияләре белән чагыштырганда авылда яшәү дәрәҗәсендә һәм сыйфатындагы шактый аерманы исәпкә алып, килеп туган вәзгыятьне федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдә дәүләт ярдәме чараларын җәлеп итеп, программа-максатчан методны куллану шартларында гына үзгәртергә мөмкин.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм аны яңарту.

Программа чараларын финанслау федераль, республика һәм муниципаль бюджетлар акчалары исәбеннән башкарыла, барлыгы – 85 405 353 (сиксән биш миллион дүрт йөз биш мең өч йөз илле өч) сум 34 тиен, шул исәптән:

- федераль бюджет акчалары - 59 304 704 (илле тугыз миллион өч йөз дүрт мең җиде йөз дүрт) сум 63 тиен;
- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 25 384 986 (егерме биш миллион өч йөз сиксән дүрт мең тугыз йөз сиксән алты) сум 81 тиен;
- муниципаль районның җирле бюджеты акчалары - 715 661 (җиде йөз унбиш мең алты йөз алтмыш бер) сум 90 тиен.

Программа кысаларында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү, авыл җирлегендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын үстерү күздә тотыла.

Дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру муниципаль районда кабул ителгән авыл территорияләрен комплекслы үстерү программасы нигезендә гамәлгә ашырыла, ул агросәнәгать комплексын үстерүнең перспектив планнары белән координациядә территориаль планлаштыру документлары нигезендә эшләнгән.

Муниципаль программа түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- авыл җирлегендә уңайлы инфраструктура шартларын булдыруга юнәлдерелгән чаралар;
- авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның төзелгән (төзелә торган) агросәнәгать комплексы объектларына территориаль планлаштыру документлары нигезендә социаль-инженерлык төзекләндерү объектлары реестры;
- чаралар гамәлгә ашырыла торган авыл җирендә агросәнәгать комплексы оешмаларында өстәмә югары технологияле эш урыннары булдыру;
- социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзегәндә заманча технологияләрне куллану;
- булган инфраструктура потенциалы катнашында авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның социаль-инженерлык төзелешенең комплекслылыгы;
- программаны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетында һәм муниципаль районның җирле бюджетларында бюджет ассигнованиеләре булу;
- программаны финанслау һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый база булу;

- авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасын комплекслы үстерү һәм торак шартларын яхшырту максатларында бюджеттан тыш акчалар җәлеп итүне стимуллаштыру чаралары булу.

Программа чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән акчалар күләме ел саен тиешле финанс елына төгәлләштерелә.

Программа чараларын җирле бюджеттан финанслау республика һәм федераль бюджетлардан финанслашу шарты белән башкарылырга мөмкин.

Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ресурсларының күләме төп чаралар кысаларында 2 нче таблицада китерелде.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләр үтәүгә финанс ярдәме күрсәтү максатларында муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирүгә бәйле Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен федераль бюджеттан финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль район бюджетына субсидияләр бирү,«Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү Кагыйдәләренең 10 пунктындагы пунктчасы, күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 12 пункты нигезендә билгеләнгән шундый ук форма нигезендә төзелә.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру рискларын анализлау һәм әлеге рисклар белән идарә итү чараларын тасвирлау.

Программаны тормышка ашыру рисклар белән бәйле, шуларның төп булганы:

- федераль законнарның үзгәрүе;
- программаны финанс белән тәэмин итүнең төрле чыганакларыннан финанслауның булмавы яисә тулысынча финансланмавы.

Программаны гамәлгә ашыру рисклары белән идарә итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасында каралган чаралардан файдалану нигезендә гамәлгә ашырылачак.

## 6. «2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү»программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Программаның максатларына ирешү авыл территорияләрендә яшәү шартларын яхшыртуга, агросәнәгать комплексында һәм тулаем авыл икътисадында инвестицион активлыкны үстерү өчен уңай шартлар тудыруга ярдәм итәчәк. Авыл территорияләрендә яшәүчеләрне, авылларда яшәүчеләрнең өлешен саклап калырга һәм барлык район халкының кимендә 10%ын тәшкил итәргә тиеш, авыл территорияләрендә арзанрак һәм уңайлырак торак булдыру, авылга һәм авыл тормышына уңай мөнәсәбәт булдыру.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
«2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районы
авыл территорияләрен комплекслы үстерү»
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында»
2025 елның 24 мартындагы
782 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләүнең индикаторлары.**

Программаның максаты-авыл җирендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру, авылга һәм авылча яшәү рәвешенә уңай караш формалаштыру.

| Бурычның атамасы | Төп чаралар атамасы | Башкаручылар | Нәтиҗәләр бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Авыл халкын һәркем сатып ала алырлык һәм комфортлы торак белән тәэмин итү | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен торак тапшыру , - **Барлыгы кв. метр:** | 2 145, 2 | 150,3 | 269,3 | 78,3 | 133,0 | 200,0 |
| | | | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту: торак урыны төзү/сатып алу, өлешләп төзүдә катнашу юлы белән | 2 145, 2 | 150,3 | 269,3 | 78,3 | 133,0 | 200,0 |
| Авыл территорияләрендә социаль һәм инженерлык төзелеше дәрәҗәсен | Авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты; Татарстан | Авыл территорияләрен төзекләндерү буенча проектлар саны, **барлыгы берәмлек:** | 7 | 3 | 2 | 2 | 4 | 15 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| күтәрү, | | Республикасы Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре; | | | | | | | |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 мартындагы 782 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«2020 - 2025 елларга Зеленодольск муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары**

Программаның максаты-авыл җирендә тормыш эшчәнлегенә уңай шартлар тудыру һәм авылга һәм авыл тормышына уңай мөнәсәбәт формалаштыру.
сумнарда

| Бурычның атамасы | Программа чарасының атамасы . | Башкаручылар | Финанслау чыганагы | Финанслау | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| **Бюджет акчалары исәбеннән барысы** | | | | **39371070, 54** | **9907000, 00** | **6720005, 00** | **7084565, 00** | **4400156, 60** | **17922556, 20** |
| Зеленодольск муниципаль районы авыл халкын һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак белән тәэмин итү | Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләрендә яшәүче гражданнар өчен торак төзү (сатып алу) | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Финанслау күләмнәре **Барлыгы:** шул исәптән акчалар хисабына: | 26188566, 00 | 1827000, 00 | 2679600, 00 | 3044160, 00 | 2003400, 00 | 1620880,3 8 |
| | | | федераль бюджет | 15038795, 64 | 1479870, 00 | 2170476, 00 | 2465769, 60 | 1622753, 99 | 1280495,5 0 |
| | | | республика бюджеты | 10890162, 36 | 347130,0 0 | 509124,0 0 | 578390,4 0 | 380646,0 1 | 340384,88 |
| | | | ЗМР җирле бюджеты | 259608,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| Зеленодольск муниципаль районының авыл территориялә рендә | Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлегендә социаль һәм | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма | Финанслау күләмнәре **Барлыгы:** шул исәптән акчалар хисабына: | 13182504, 54 | 8080000, 00 | 4040405, 00 | 4040405, 00 | 2396756, 60 | 16301675, 82 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| социаль һәм инженерлык төзеклеге дәрәҗәсен арттыру | инженерлык инфраструктурасын үстерү | комитеты; Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре; | федераль бюджет | 7494190,00 | 6480000,00 | 3240000,00 | 3240000,00 | 1914030,00 | 12878323,90 |
| | | | республика бюджеты | 5426827,24 | 1520000,00 | 760000,00 | 760000,00 | 448970,00 | 3423351,92 |
| | | | ЗМР җирле бюджеты | 261487,30 | 80000,00 | 40405,00 | 40405,00 | 33756,60 | 0,00 |